Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советының уникенче утырышы

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

8 июль, 2021 ел №

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Ленино-Кокушкино авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару Кагыйдәләрен раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Ленино-Кокушкино авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча ачык тыңлаулар беркетмәсен һәм 2021 елның 30 июнендәге Бәяләмәне исәпкә алып, **Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы карар кабул итте:**

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Ленино-Кокушкино авыл жирлеге муниципаль берәмлегенең жирдән файдалану һәм төзү кагыйдәләрен расларга.

2. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Башкарма комитеты жир биләмәләреннән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Ленино-Кокушкино авыл жирлеге муниципаль берәмлегенең территориаль планлаштыру Федераль дәүләт мәгълүмат системасының рәсми сайтында (https://fgistp.economy.gov.ru/) урнаштыруны тәэмин итәргә .

3. Питрәч муниципаль районы Ленино-Кокушкино авыл жирлеге Советына элек кабул ителгән карарның «Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Ленино-Кокушкино авыл жирлеге муниципаль берәмлегенең жир биләмәләреннән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында» 2014 елның 18 декабрендәге 25 номерлы карары (2018 елның 12 мартындагы 52 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка житкерергә).

5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советының җирлекләрнең җирле үзидарә органнары белән үзара эшчәнлек, законлылык, хокук тәртибе һәм регламенты буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Питрәч муниципаль районы башлыгы И.М. Кашапов